Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Алешкин-Саплык урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең адресын үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2014 елның 19 декабрендәге 46/4 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару тәртибен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының "Алешкин-Саплык урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең урнашу урынын түбәндәге адрестан үзгәртергә: 422478, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Алешкин-Саплык авылы, мәктәп урамы, 8 йорт адресын - 422478, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Татар Саплыгы авылы, мәктәп урамы, 2б адресына.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Алешкин-Саплык урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры М.Э. Хәлиулловны юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында булган юридик зат турында белешмәләргә үзгәрешләр теркәүгә документлар биргәндә Татарстан Республикасы буенча Россия салым хезмәте органнарында чыгыш ясарга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: М.Р. Гафаров